Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының Данауровка авыл җирлеге Советы
карары

2020 елның 14 мае　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　№ 84/3

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Данауровка авыл җирлегенең
җирдән файдалану һәм төзелеш
Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

2014 елның 7 гыйнварындагы 10/1 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Данауровка авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы мәгълүматны тыңлап һәм фикер алышканнан соң, Чистай муниципаль районының Данауровка авыл җирлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре буенча комиссия бәяләмәсен һәм 2020 елның 27 февралендә уздырылган ачык тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Данауровка авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Чистай муниципаль районы «Данауровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре территорияләрен шәһәр төзелешен зоналаштыру картасына «Индивидуаль торак төзелеше зонасы» территориясе чикләрен үзгәртү һәм 16:42:180207:61 кадастр номеры булган җир кишәрлеге территориясен «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектлар зонасы»на кертү өлешендә үзгәреш кертергә.
2. Әлеге карарны игълан тактасында бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://chistopol.tatarstan.ru).
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Данауровка авыл җирлеге
башлыгы:　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　В.К. Сәдретдинова

2020 елның 14 маендагы 84/3 номерлы карарына
1 нче кушымта

Чистай муниципаль районы «Данауровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре территорияләрен Шәһәр төзелеше зоналарына бүлү картасы

Гамәлдәге нигезләмә:




Кертелә торган үзгәрешләр:

